**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**РУС ӘҖИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**2015 елның 30 декабре** **№16**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

12.06.2002 Федераль законның 15 статьясы нигезендә «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Зеленодольск муниципаль районы «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 10 статьясы, Рус Әҗиле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 елның 28 декабрендә кабул ителгән 17 санлы «Җирле референдумны үткәрү инициативасы турында» карары, Рус Әҗиле авыл җирлеге Советының 2015 елның 28 декабрендә кабул ителгән 15 номерлы «Җирле референдумны үткәрү инициативасы турында» карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.2016 елның 6 мартына Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2.Утвердить вопрос, выносимый на местный референдум:

«2016 елда Рус Әҗиле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә һәм алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

| № | Гражданнарның үзара салым акчаларын тоту юнәлеше | Үзара салым акчаларын тоту күләме гражданнар (сум) |
|---|---|---|
| 1. | Җирлек территориясен төзекләндерү, шул исәптән моның өчен кирәкле төзелеш материаллары һәм кече архитектура формаларын сатып алу. | 300 000 |

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Рус Әҗиле авылы, Центральная урамы, 1 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Карашам авылы, Новая урамы, 27 йорт (мәдәният йорты бинасы).

**Рус Әҗиле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе Г.Ф. Семахина**